Республика Татарстан
СОВЕТ ВЕРХНЕСИМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422055, Республика Татарстан, с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422055, Татарстан Республикасы, Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

23.09.2019 № 16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 16.01.2012 елгы №3 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә” үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.02.2019 елгы №127 “Татарстан Республикасы мәнфәгатләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” карарына туры китереп, Югары Симет авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибен раслау турында” 16.01.2012 елгы №3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны “Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге белән каралган очраклардан тыш” сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 3 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“3. Ачык сервитут:

1) җир участогы аша үтү яки бару, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектлары яки аның яр буе полосаларына иректе керүе максатында;

2) җир участогына межалау билгеләрен, дәүләт геодезик челтәрләренең геодезик пунктларын, гравиметрик пунктлар, нивелир пунктлар һәм аларга якын килү юлларын урнаштыру;

3) җир участогында дренаж эшләре уздыру;

4) су объектларыннан су ресурсларын алганда;

5) җир участогы аша авыл хуҗалыгы хайваннарын куып алып чыкканда;

6) җир участогында билгеләнгән шартларда җирле шартларга һәм гореф-гадәтләргә срогы туры килгәндә, печән чабу, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү;

7) җир кишәрлеген ау һәм балык тоту, аквакультура( балык үрчетү) максатларында кулланган очракларда билгеләнә".

1.3. 15 пунктның беренче абзацында "җир участогының кадастр паспортына" сүзләрен "күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына" сүзләре белән алыштырырга;

1.4. 16 пунктның өченче абзацында "күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрына" сүзләрен "күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына" сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/simet адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Р.Әхмәдуллин